Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Советының икенче утырышы

Кощаково авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

09.11.2020 ел № 9

Кощаково авыл җирлеге территориясендә гражданнарның җыелышларын һәм конференцияләрен билгеләү һәм уздыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Кощаково авыл җирлеге Советының 2007 елның 04 октябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Кощаково авыл җирлеге территориясендә гражданнарның җыелышларын һәм конференцияләрен билгеләү һәм үткәрү тәртибен китерү максатларында **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге советы карар кабул итте:**

1. Кощаково авыл җирлеге Советы карары белән расланган Кощаково авыл җирлеге территориясендә гражданнарның җыелышларын һәм конференцияләрен билгеләү һәм үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Кощаково авыл җирлеге җирле үзидарәсенең вазыйфаи затлары» сүзләреннән соң 1 өлешнең 1.2 пунктчасында «инициатив проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре турында фикер алышу» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кощаково авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова